СОВЕТ БАВЛИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БАУЛЫ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ СОВЕТЫ

РЕШЕНИЕ КАРАР

12.04.2024 Баулы шәһәре № 244

Баулы муниципаль район Советының 2019 елның 16 октябрендәге 222 номерлы «Баулы муниципаль районында бюджет төзелеше һәм бюджет процессы турындагы Нигезләмәне раслау турында» карарына үзгәрешләр кертү турында

«Россия Федерациясе Бюджет кодексына һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2023 елның 25 декабрендәге 628-ФЗ номерлы Федераль законына ярашлы, Баулы муниципаль район Советы КАРАР ИТТЕ:

1. Баулы муниципаль район Советының 2019 елның 16 октябрендәге 222 номерлы «Баулы муниципаль районында бюджет төзелеше һәм бюджет процессы турындагы Нигезләмәне раслау турында» карарына ( Баулы муниципаль район Советының 2020 елның 29 маендагы 262 номерлы, 2021 елның 14 декабрендәге 91 номерлы, 11.04.2022 елның 11 апрелендәге 110 номерлы, 2022 елның 18 августындагы 126 номерлы, 2023 елның 2 февралендәге 162 номерлы, 2023 елның 20 июнендәге 191 номерлы, 2023 елның 26 октябрендәге 222 номерлы, 2023 елның 14 декабрендәге 232 номерлы карарлары белән кертелгән үзгәрешләр белән) түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

8 статьяның 5 пунктын түбәндәге эчтәлектәге абзац белән тулыландырырга:

«иҗтимагый финанслар белән идарә итүнең дәүләт интеграцияләнгән мәгълүмати системасында «Электрон бюджет» капиталь төзелеш объектлары һәм күчемсез милек объектлары турында мәгълүмат формалаштыра, аларга капиталь кертемнәрне финанс белән тәэмин итү (финанслау) чыганагы булып федераль бюджет акчалары тора (капиталь төзелеш объектларыннан һәм дәүләт оборона заказына кертелгән күчемсез милек объектларыннан тыш)».

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында (http://www.pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы сайтында (http://www.bavly.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга.

Баулы муниципаль районы Башлыгы,
район Советы Рәисе И.И. Гозәеров